ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.02.2024 Мөслим авылы № 65

**«Татарстан Республикасы Мөслим районының спорт резервын алдан әзерләү буенча «Яшьлек» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында**

1. Кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы «Яшьлек» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәт шартлары турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы «Яшьлек» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларының хезмәткә түләү шартлары турында нигезләмә;

2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнә торган өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Яшьлек «спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең хезмәт хакы, әлеге карарның нигезендә хезмәткә түләүнең яңа шартларына күчкән вакытта гамәлдә булган хезмәткә түләү системасы нигезендә түләнә торган хезмәт хакыннан ким булмаска тиеш, хезмәткәрләрнең вазифа бурычлары күләмен саклау һәм шул ук квалификациядәге эшләрне башкару шарты белән.

3. Россия Федерациясе Хезмәт кодексына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Яшьлек» спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе директорына:

хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган коллектив шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив актларга тиешле үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга https://miisliimovo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Салихҗанов**